ӨМЕТЛӘР АКЛАНЫРМЫ?
«ВТ» хәбәрчесенең дөньядагы вакыйгаларга карашы
> 2

АЛТЫН СЫЕР
Россиянең иң кәттә сыеры Яшел Үзәндә яши
> 3

РАШАД ФӘТКУЛЛИН:
«Татарстанда нефть ятмалары тагын йөз елга җитәчәк әле»
> 4

ХӘТӘР ТӨЙМӘ
ОРВИны антибиотикларсыз дәвалый башлаячаклар
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 153 (29120) | Чәршәмбе | 18 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Яшәеш

Ана капиталын файдаланып, торак сатып алу эше катлауланырга мөмкин. Россия Дәүләт Думасы депутатлары бала акчасын фәкать опека органнары ризалыгы белән генә тотарга рөхсәт итмәкче. Яңалык ана капиталын әле туздырырга өлгермәгән әти-әниләргә кагыла. Шул рәвешле, балага дип бирелгән түләүне законсыз рәвештә «тере» акчага әйләндерүгә чик куймакчылар.

Яңалыкны Дәүләт Думасының Төзелеш һәм ТКХ комитеты депутатлары тәкъдим иткән. Алар әйтүенчә, бу ана капиталы тирәсендә «кул уйнату» очракларын киметергә ярдәм итәчәк. Рәсми саннардан күренгәнчә, ил күләмендә әлеге төр түләүне законсыз рәвештә «тере» акчага әйләндерергә теләүчеләргә каршы ел саен 2–2,5 мең хөкем карары чыгарыла.

– Канун проекты хуплау тапкан очракта, торак сатып алганда ана капиталын фәкать опека органнары рөхсәте белән генә файдаланырга мөмкин булачак, – дип ачыклык керткән Төзелеш һәм ТКХ комитеты депутаты Сергей Колунов.

Бүген исә бала акчасы кергән фатирны сатып, яңасын алырга теләгән әти-әниләргә генә опека органы ишеген шакырга туры килә. Әлеге юлны таптаган әни буларак, шунысын да әйтергә кирәк: бер дә җиңел эш түгел ул. Беренчедән, тиешле документны шактый озак әзерләсәләр (ә милек саткан-алганда һәр көн кадерле), икенчедән, сиңа кирәкле фатир сатучыларның опека органнары белән бик бәйләнеп торасы килми. Опека органнары яңа алыначак торакка да шактый таләпләр куя. Яңалык гамәлгә керсә, ана капиталы акчасына торак сатып алырга теләгән бөтен әти-әниләр бер хәлгә төшәчәк.

Россия Социаль фондының Татарстандагы идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, бу елның беренче яртысында республикада яшәүче 9942 гаилә ана капиталын торак шартларын яхшыртуга файдаланган. Әлеге максатта 5,9 миллиард сум акча тотылган.

Билгеле булганча, ана капиталы программасы илдә 2007 елдан бирле гамәлдә. Баштарак аны гаиләдәге икенче сабыйга гына бирсәләр, 2020 елдан ярдәм чарасын тәүге тапкыр әти-әни булучылар да ала башлады. Әлеге акчаны торак шартларын яхшырту, балаларга белем бирү, әнинең булачак пенсиясе, инвалид

АНА КАПИТАЛЫНЫҢ КҮЛӘМЕ (сумнарда)

2023	Беренче балага	616300
	Икенче балага	198100
	Икенче балага*	814400
2024	Беренче балага	653900
	Икенче балага	210200
	Икенче балага*	864100

*Беренче бала 2020 елга кадәр туган булса

Илдар Мөхәммәтҗанов

ХИКМӘТЛЕ АКЧА

баланы социаль адаптацияләү өчен товарлар (хезмәтләр) һәм балаларга айлык түләү өчен тотарга мөмкин.

– Яңалык милек базарында үтә күренмәлелекне тәэмин итәргә булышачак, – ди риэлтор Наилә Галиева. – Югыйсә намуссыз риэлторлар арасында ана капиталын «тере» акчага әйләндерү белән шөгыльләнүчеләр артканнан-арта. Авылда ялган документлар ярдәмендә иске йортларны чүп бәясенә сатып алалар да бала акчасын кесәгә салып куялар. Нәтиҗәдә чип-чиста татар авылларына да төрле милләт вәкилләре кайтып төпләнә.

Авыл язмышын өсте-өстенә закон чыгарып кына хәл итеп бетереп булмый анысы. Кайбыч районының Кошман авылында четерекле хәлдән чыгу җаен тапканнар әнә.

– Бездә читтән кайтып урнашучыларга бәйле проблема юк, – ди Кошман авыл җирлеге башлыгы Лилия Сафина. – Район үзәгенә якын булгангамы, Кошман буш йортлар күп булган салалар рәтенә керми. Яшьләр дә үзебездә кала. Авылдагы нигезне сатарга җыенучылар турында ишетсәк, йортны чит кешеләргә сатмасагыз иде, дигән тәкъдимебезне җиткерәбез. Мәҗбүр итеп әйтә алмыйбыз, билгеле. Киңәш кенә итәбез. Элек авылда ничек матур яшәгән булсак, хәзер дә шулай бердәм булып гомер итәсе иде. Хәзер җирле үзидарәләр йортны сатканны-алганны белмичә дә кала. Элеккеге кебек төртип юк хәзер. Авылда бер йортны таҗик гаиләсе сатып алды. Алар белән баштан ук сөйләшеп куйдык. Җайлы кешеләргә охшаганнар. Балалары бакчага йөри. Бөтен районыбызда җәй көне ике генә балалар бакчасы эшли. Берсе район үзәгендә булса, икенчесе – бездә. 2020 елда авылда илле урынга исәпләнгән балалар бакчасы төзелде. Анда бүген кырыктан артык бала йөри. Быел авылыбызда тугыз бала туды. Димәк, киләчәккә өмет бар.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Фикер

Тимур КАКОХО, Россия юристлары ассоциациясенең Татарстандагы төбәк бүлеге башкарма комитеты рәисе, Татарстан Иҗтимагый палатасының Хокукый мәсьәләләр һәм иҗтимагый күзәтчелек буенча комиссиясе җитәкчесе:
– Кырыгалдарлар кешелек тарихында булган, бар һәм булачак. Тик төрле мошенниклык схемаларына каршы көрәш чарасы буларак, ана капиталы ярдәмендә торак сатып алу шартларын катгыйлатканда гаилә мәнфәгатьләре турында да онытырга ярамый. Сертификатка ия булучыларның акчаны тиешле шартларда тиз һәм үзләренә уңайлы итеп файдалану хокукын саклап калу зарур. Ни генә дисәң дә, вакыт – акча. Бу эштә һәр ике якның да мәнфәгатьләре исәпкә алынырга тиеш.

Әйбәт бюджет

2024–2026 елларга Татарстанда муниципаль берәмлекләрнең бюджетлары дефицитсыз булачак. Финанс министрының беренче урынбасары – Казначылык департаменты директоры Марат Фәйзрахманов әйтүенчә, 45 муниципаль район һәм шәһәр округының, 91 җирлекнең бюджеты буенча фаразлар булдырылган. Аларның барысы да дефицитсыз, ягъни чыгымнары керемнәргә туры килә.

Исегезгә төшерәбез: 2024 елга һәм 2025–2026 еллар план чорына Татарстан бюджеты проекты узган атна башында Дәүләт Советына карап тикшерүгә кертелде.

Ярдәмнең артыгы юк

Казаннан Луганск Халык Республикасының Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә быел инде җиденче тапкыр гуманитар йөк җибәрелде. Бу юлы аның авырлыгы – 90 тонна.

Казан мэриясе хәбәр иткәнчә, ике йөк машинасы Татарстан карамагындагы шәһәрләргә төзелеш материаллары, автомобильләргә запас частьлар, пыяла, көнкүреш химиясе, тиз бозылмый торган ризыклар, кием-салым, дарулар илтә киткән. Республика карамагындагы шәһәрләрдә яшәүчеләргә 40 тонна яшелчә, 15 тонна балалар кирәк-ярагы, көнкүреш химиясе, медицина битлекләре, тиз бозылмый торган ризыклар китереләчәк. Йөкнең бер өлеше кимерүчеләргә каршы агудан (15 тонна) гыйбарәт. Ярдәмне «Добрая Казань» оешмасы шәһәр халкы һәм җирле эшмәкәрләр белән бергәләшеп җыйган.

Исегезгә төшерәбез: сентябрь ахырында Казаннан ун йөк машинасы бу шәһәрләргә азык-төлек, укучылар өчен дәреслекләр, җылы кием-салым, урын кирәк-ярагы алып килде. Август аенда Татарстан башкаласыннан 85 тонна йөк озатылган иде.

Һаман үсә

Сентябрь аенда Татарстанда инфляция күләме 5 процентка җиткән. Татарстанстат мәгълүматлары буенча, августта бу күрсәткеч 4,29 процент тәшкил иткән булган.

Шул ук вакытта узган айда бәяләр алдагы айдагы белән чагыштырганда 0,66 процентка арткан.

Гомумән, быел тугыз ай эчендә – гыйнвардан сентябрьгә кадәр – инфляция күрсәткече 4,38 процентка (узган елның шушы ук чорындагыга караганда 0,08 процентка артык) күтәрелгән. Ә инде бәяләр шушы чорда 3,55 процентка үскән. Көзнең беренче аенда бигрәк тә яшелчә кыйммәтләнгән (узган елдагы белән чагыштырганда – 27,99 процентка).

Ватан хакына

Үзебезнекеләр өчен

Ярдәм чаралары, борчыган сорауларга җаваплар, хәрбиләр һәм аларның гаиләләре кичергән язмышлар... 17 октябрьдә Татарстанда контракт буенча хезмәткә багышланган 12 сәгатьлек «Все СВОи» патриотик телемарафоны узды. Иртәнге уннан кичке унга кадәр ТНВ телеканалы, башка матбугат чаралары һәм социаль челтәрләрдә барган туры эфирда нинди мөһим фикерләр әйтелде?

Алар безгә яшәргә, чын хатын-кыз булып калырга мөмкинлек бирә. Татарстан Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыеваның туры эфир вакытында махсус хәрби операция зонасындагы егетләр турында әйткән сүзләре бу.

– Хатын-кыз буларак, махсус хәрби операциядә катнашучы егетләребез белән очрашкан саен, алар белән чын күңелдән горурлануыбыз турында кабатлап туя алмыйм, – диде ул.

Фазлыева шулай ук хәрби бурычларын үтәүче егетләргә һәм аларның гаиләләренә Татарстан Хөкүмәте күрсәтә торган ярдәм чаралары турында искәртте.

– Республикада махсус хәрби операциядә катнашучыларның 18 яше тулмаган балаларына бер мәртәбә бирелә торган 20 мең сумлык түләү каралган. Бүген 12763 бала әлеге ярдәм чарасы белән тәэмин ителде. Моннан тыш, балаларга белем алу юнәлешендә дә ярдәм күрсәтелә. Алар уку йортларына беренче чиратта кабул ителә. Яңа туган балаларга исә махсус җыелмалар бүләк итәбез, – дип сөйләде вице-премьер.

Контракт төзегән очракта каралган матди ярдәм турында да әйттеләр туры эфир барышында. Әлеге ярдәмнең күләме, контракт төзү тәртибе турында Казандагы контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алу пункты башлыгы Евгений Токмаков сөйләде.

– Россия Оборона министрлыгы белән контракт төзегән кешегә 195 мең сум күләмендәге түләү каралган. Ул бер мәртәбә бирелә. Моннан тыш, иң кирәкле хәрби вазыйфаларны сайлаучыларга һәм хәрби тәҗрибәгә ия булучыларга ДОСААФ тарафыннан 105 мең сум күләмендәге түләү каралган. Ул шулай ук бер мәртәбә бирелә, – диде ул.

Контракт буенча хәрби хезмәткә китәргә тәвәккәлләүчеләр Казандагы «Батыр» үзәгенә яки җирле хәрби комиссариатка мөрәҗәгать итә ала.

– Сораулар була калса, 117 номеры буенча «кайнар линия»гә шалтыратырга мөмкин. Белгечләребез кая барасын да, нинди документлар кирәк булуын да аңлатачак. Шулай ук Дәүләт хезмәтләре сайтында да махсус бүлек бар, тулырак мәгълүматны аннан табарга була.

Исегезгә төшерәбез:
- **Оборона министрлыгы белән контрактны 18–60 яшьлекләр төзи ала. Моннан тыш, сирәк очрый торган белгечлеге булганнарның яше 65кә кадәр җитәргә мөмкин;**
- **117 номерлы «кайнар линия» тәүлек дәвамында эшли. Контракт буенча хәрби хезмәт турындагы мәгълүматны heroes-tatarstan.ru сайты аша да табарга мөмкин;**
- **контракт төзегәндә, документлардан паспорт һәм хәрби билет кирәк.**

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Ярослав НИЛОВ, Россия Дәүләт Думасының Хезмәт, социаль сәясәт һәм ветераннар эшләре буенча комитет рәисе:

Машинаны эвакуацияләү алдыннан бу хакта аның хуҗасына хәбәр итүне гамәлгә кертергә кирәк. Кешегә тиз арада килеп, машинасын тиешле җиргә күчереп куяр өчен 10–15 минут вакыт бирергә кирәк. Ул рөхсәт ителмәгән урынга куйган өчен штрафын барыбер түләячәк, билгеле. Әмма машинасы эвакуацияләнмәячәк.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – АЙЛЫК КЕРЕМ

РИА «Новости» мәгълүмат агентлыгы белгечләре 2023 елның II кварталында Россиядә бер кешегә туры килә торган айлык керем күләмен исәпләгән. Рейтингның беренче урынында Ямал-Ненец автономияле округы булса, соңгы урында – Карачай-Черкес Республикасы.

Рейтингтагы урыны	Төбәк	Айлык керем күләме, сумнарда
1	Ямал-Ненец автономияле округы	140,3 мең
2	Чукотка автономияле округы	131,6 мең
3	Ненец автономияле округы	114 мең
4	Мәскәү	99,6 мең
...		
9	Татарстан	51,3 мең

Шәп каба!

Татарстанда балык тоту өчен иң кулай урыннарны атап үткәннәр. «Яндекс Путешествия» сервисы мәгълүматларына караганда, көзен Идел, Чулман, Нократ һәм Мәләкәс елгаларында балык бик шәп каба.

Иделдә 70 төрдән артыграк балык (шул исәптән судак, чуртан һәм берш) исәпләнә. Көз көне кармакка күбрәк чуртан, корбан балыгы (лещ) һәм кәрәкә (карась) эләгә. Шулай ук алабуга (окунь), җәен (сом) һәм сазан да тотарга мөмкин.

Чулманның балыклы урыннары – Алабуганың Шайтан каласы янәшәсендә һәм Идел елгасы белән кисешкән җирендә. Ноябрь аенда биредә судак, алабуга, чуртан, жумба (налим) күп була. Нократ елгасыннан балык тоту өчен исә Мамадышка барырга кирәк. Ә инде Чаллыда яшәүче балыкчылар Мәләкәс елгасын үз итә. Анда Габдулла Тукай исемендәге яр буе тирәсендә карп һәм сазан бик әйбәт эләгә.

«ВТ» архивыннан



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

МӨСЕЛМАННАРГА АЮ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮ

Израиль – Фәләстыйн конфликты уңаеннан бөтен дөньяда идеологик көрәш җәелдерелә. АКШ сенаторы Линдси Грэм: «Без дини сугыш алып барабыз, һәм мин Израиль ягында. Нәрсә таләп ителсә, барысын да эшләгез. Ул урынны (Газзәне әйтә) җир белән тигезләгез», – дип белдерде. ХАМАСны монстрлар итеп күрсәтү, барлык фәләстыйнлыларны еркһкылар итеп гәүдәләндерү өчен, бөтен Көнбатыш матбугаты һәм сәясәтчеләре бар көчләренә тырыша. Барлык мәгълүмат чаралары сионнылар кулында булганлыктан, моны эшләү аларга кыен түгел. Әмма шулай да хакыйкать барыбер өскә калкып чыга. Күп кенә Европа илләрендә, Фәләстыйнны яклап, протест акцияләре үткәрү тыелса да, Газзә секторында Израиль алып барган вәхшәткә каршы күпмеңле акцияләр оешып тора. Шунысы кызык: кайбер европалы сәясәтчеләр дә хакыйкатьне аңлый һәм яклый. Испаниянең социаль сәясәт министры вазыйфаларын башкаручы Ионе Беларра: «Израиль Газзә секторында планлаштырылган геноцид алып бара», – дип белдерде һәм Премьер Нетаньяхуны Халыкара җинаятьләр суды хәрби җинаятьче буларак хөкем итәргә тиешлеген әйтте.

Латин Америкасы илләрендә Фәләстыйнны яклау хәрәкәте көчле. Колумбия Президенты Густаво Петро сиончыларның Газзәне бомбага тотуын «варварлык» дип бәяләде: «Мәхәббәткә нигезләнгән дин туган илдә һәр 15 минут саен сабыйлар үтерелә», – диде.

Сиончылар алып барган геноцидка каршы чыгучы гыйбриләр дә байтак. Ортодоксаль яһүдләр Израильнең үзендә дә, Америкада да протест акцияләре уздырды, монысына гаҗәпләнмибез, чөнки алар һәрвакыт Израильгә каршы. Нью-Йоркта берничә йөз гыйбри (ортодокслар түгел, гадәти активистлар) Ак йорт каршындагы урамны япты һәм Израильнең хәрби хәрәкәтләренә ярдәмне туктатуны таләп итте. Дэн Шилон – атаклы Израиль журналисты – Нетаньяхуны судка бирергә чакырды: «Ул – хәрби җинаятьче», – диде.

Сиончылар ХАМАСны 7 октябрь һөҗүмендә күпләп тыныч халыкны үтерүдә гаепли. Үтереш урынында булган өч бала анасы израильле Ясмин Порат Израильнең 12 каналына интервью бирде һәм, кешеләрне ХАМАС түгел, Израиль хәрбиләре үтерде, диде.

Европада мәгълүмат көрәше аз гына мөселманнар файдасына авыша башлаган иде, Брюссельдә бер ИГИЛ* вәкиле ике футбол җанатарын үтерде һәм моны мөселманнар өчен үч алу дип атады. Мөселманнар моны «аю хезмәте» дип бәяләде, ИГИЛ һәрвакыт мөселманнарга каршы сугышты, беркайчан да аларны якламады, дип бәяләделәр.

*Россиядә тыелган оешма

Россиядә

НЕФТЬ ӨЧЕН ЮАНЬНАР

Федераль хөкүмәт вице-премьеры Новак: «Нефть бәясе 2035 елга кадәр баррельгә 100 доллар тирәсендә торачак», – дип белдерде. Россия «кара алтын»ына дисконт та бик нык кимегән икән. Алдагы елда 35 доллар тирәсе булса, хәзер 12–13 доллардан артмый. Бюджет өчен яхшы хәбәр бу. Финанс министры Силуановның һәр чыгышы соңгы вакытларда оптимизм белән сугарылган. Аның фикеренчә, 2024–2026 елгы бюджетын хәрби бюджет дип атап булмый, чөнки иң күп чыгымнар социаль тармакка карый. Төп салымнарны күтәрү мәсьәләсен дә 2027 елга кадәр кичектерергә булганнар. Петербург Икътисад форумында Силуанов белән Решетников (икътисадый үсеш министры) салымнарны, шул исәптән физик затларның керемнәрә салымны да күтәрү кирәклеге турында сөйләгәннәр иде. «Кара алтын» бәясе чүпрә кебек кабарганда, ул идеяне кирәге калмаган.

Җир мае бәясен фаразлау, бигрәк тә озак сроклы перспективада күпме буласын алдан әйтү мөмкин түгел ләкин. Һава торышын фаразлау шикелле рәк. Германиядә әнә рецессия башланды, диләр. АКШ Венесуэла белән килешү төзеп килә: ирекле сайлаулар үткәрү шарты белән санкцияләрне аларга вәгъдә итә. Иран белән дә шулайрак тота үзен. Бу ике ил нефте составы белән Россиянекен алыштыра, алар базарга күпләп чыкса, бәяләр гомумән дә төшәчәк, Россиянекенә дисконт та үсәчәк. Бюджеты нефть куелышында юраулрга карап төзү бер дә ышанычлы түгел.

Россия «кара алтын»ын сатуның бер нечкә һәм уңайсыз ягы кала бирә. Милли валюталарга сатарга туры килә, чөнки долларлар белән түләсәләр, санкцияләр кармагына кабасың: а) түшәм бәядән уза алмыйсың, ә) долларны Россиягә кертү бик авыр. Россия нефтен күпләп алучы Һиндстан белән эшләр аеручa хөрти. Рупиягә сатсаң, Һинд банкларында еләнә дә кала. Кыйммәтле чималны банк компьютерындагы санга алыштырасың, ул саннан Россиягә файда юк. Шуңа күрә Мәскәү Дәһлидән юань белән түләүне сорый. Юань да резерв валютасы түгел, әмма ул рупиягә караганда чут кенә ярыйсы. Һиндстан хакимиятләре яңа формуланы бик ошатып бетерми икән. Нефть эшкәртү заводлары «кара алтын»ны алганнар, әмма җиде партия нефтькә түләү тоткарлана. Сентябрь ахырында ук нефтьне бензинга әйләндергәннәр инде – акча юк. Юань белән түләү кыйммәткә төшә: башта рупияне Гонконг долларына алыштырасың, аннан юаньга. Алыштырган саен комиссия түлисең. Шуңа күрә нефть сатыла, акчасы бюджетка кайтып җитәме-юкмы икәне мәгълүм түгел әле.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

ЫШАНЫЧЛЫ ИСКЕ ДУС

Дәүләт Советында Татарстан белән Беларусь төбәкләре арасындагы хезмәттәшлек турында сөйләштеләр. Фәрит Мөхәммәтшин Беларусь һәм Россия Берлеге Парламент Җыенының Энергетика һәм транспорт буенча комиссиясе әгъзалары белән очрашты.

tatarstan.ru

«Татарстан Беларусь төбәкләре белән актив хезмәттәшлек итә, үн ел дәвамында Беларусь республикабызның тышкы сәүдә буенча төп партнерларыннан берсе санала», – диде Фәрит Мөхәммәтшин очрашуда. 2022 елда Татарстан белән Беларусь төбәкләре арасында сәүдә әйләнеше 800 млн доллардан артып киткән.

2004 елда ике арада сәүдә-икътисади, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турында хөкүмәтара килешү имзаланган иде. Һәр өч ел саен аны гамәлгә ашыру буенча чаралар планы кабул ителә. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, парламентара элемтәләр дә ныгый. «Ике ил төбәкләренең еллык форумнары барышында Дәүләт Советы җитәкчелеге актив катнаша», – диде ул. Төбәкләр һәм район-шәһәрләр арасында да элемтәләр бар. Әйтик, узган ел Татарстан Дәүләт Советы һәм Минск өлкәсе Депутатлар Советы арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. Быел исә Балык Бистәсе районы һәм Минск өлкәсенең Стародорожский районы тәҗрибә уртаклашырга килештеләр. Минск белән Казан арасында яңа килешү әзерләнә. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, Татарстан белән Беларусь төбәкләренең хезмәттәшлеге санкцияләр шартларында көчәя төшкән. «Бер-беребез өчен тагын да киргәрәк булдык, санкцияләр безне тагын да якынаюга, икътисадый һәм гуманитар мәсьәләләрдә тыгызрак хезмәттәшлеккә этәрде. Бүген безнең предприятиеләрнең актив хезмәттәшлеге дәвам итә», – диде ул. Республика кырларында Беларусьтан кайтартылган техника эшли, шәһәрләрдә бу илдә җитештерелгән җәмәгать транспорты йөри.

Парламент Җыенының Энергетика һәм транспорт буенча комиссиясе рәисе Алексей Кушнаренко фикеренчә, ике арада яхшы хезмәттәшлек, үзара аңлашу һәм дуслык мөнәсәбәтләре урнашты. Әмма курсәткечләрне арттыру мөмкинлеге дә бар әле. Бу хакта ул комиссия утырышында тагын бер мәртәбә әйтте. Татарстан белән Беларусь төбәкләре арасындагы сәүдә әйләнешен 2 млрд долларга җиткерүне максат итеп куярга кирәк. «Татарстан һәм Беларусь Республикасының өч йөздән артык компаниясе импортны алмаштыру юнәлешендә уңышлы эшли», – диде ул.

Утырышта катнашучылар Беларусь һәм Россия төбәкләре арасында пассажирлар авиациясен субсидияләү турында да фикер алыштылар. Чарада 2023 елның беренче яртыеллыгында Союз дәүләте бюджетының үтәлеше, Берләшкән транспорт системасы эше, энергетика һәм транспорт базарын көйләү һәм башка мәсьәләләр дә каралды.

ҮЗЕБЕЗНЕКЕЛӘР ӨЧЕН

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Алименттан качып булмый

Ярдәмнең төрлесе бар. Әйтик, суд приставлары махсус хәрби операциядә катнашучы 12 меңләп татарстанлыга карата ачылган эшне туктаткан. Бу турыда Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча баш идарәсенең башкарма производствоны оештыру бүлеге җитәкчесе Альберт Ибәтуллин сөйләде.

– Бурычы булган кеше махсус хәрби операциядә катнаша икән, аңа карата эшләр туктатыла. Моңа бары ике категория элəкми – алимент түләүчеләр һәм түгендыручының үлеме сәбәпле китерелгән зыянны каплаучылар. Эшне туктатып тору турында гариза бирүнең бүген берничә юлы бар. Хәрби хезмәткәр аны контракт төзегәндә үзе бирә ала, ул турыдан-туры суд приставлары хезмәтенә әләгәчәк, яки дистанцион рәвештә Дәүләт хезмәтләре порталында яки Купфункцияле үзәктә бирергә мөмкин, – дип аңлатты ул.

Хәләл ярдәм

Инде әйтелгәнчә, махсус хәрби операциядә катнашучыларга да, аларның якыннарына да ярдәмнән ташламый-лар. Шул форсаттан оештырылган «Ватанны саклаучылар» дәүләт фонды да хәрби хәрәкәтләр зонасында булган ветераннар һәм сугышчыларның гаилә әгъзаларына һәрьяклап ярдәм күрсәтү белән шөгыльләнә. Фондның республикадагы филиалы җитәкчесе Гүзәл Удачина әлеге оешмада эшләүчеләр турында сөйләде.

– Фондта 45 социаль координатор эшли. 1 июньнән бирле безгә 3600ләп кеше мөрәҗәгать итте. Ярдәм сорап, махсус хәрби операциядә катнашучылар үзләре дә, аларның гаилә әгъзалары да килә. Координаторларның бурычы – тиешле ярдәм күрсәтү, юнәлеш бирү. Аларны ипгибар белән сайладык. Араларында хәрбиләрнең хатыннары, социаль хезмәткәрләр, хәрби хезмәт ветераннары бар. Алар – чын профессионал. Ә иң мөһиме – психологик яктан әзер кешеләр, – диде ул.

Тиздән хәрбиләр һәм аларның гаиләләренә ярдәм чаралары турындагы сорауларны махсус чат-ботка юлларга мөмкин булачак. Бу хакта Гүзәл Удачина хәбәр итте.

3 ай эчендә – 8 млн сум! «Зәкят» хәйрия фонды махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм йөзеннән җыйган акча бу. Фонд тагын нилер белән ярдәм итә? Аның җитәкчесе Булат Мәрданов туры эфирда әнә шул турыда сөйләде.

– Узган елның өч аенда безнең фонд махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен 8 млн сум акча җыйды. Битараф булмаган кешеләр тарафыннан җыелды ул. Гомумән алганда, бер ел эчендә без егетләргә 10 млн сумлык ярдәм күрсәттек, – диде ул. – Көз айларында иң күп акчаны җылы кием-салымга һәм азык-төлеккә юнәлтергә тырышабыз. Моннан тыш, фонд хәләл ризык белән тәэмин итүне дә оештырды.

Районнарда ни хәлләр?

12 сәгать дәвам иткән телемарафонда Татарстан районнары башлыклары да катнашты. Үзләрендә булган ярдәм чаралары турында сөйләде алар.

Әйтик, Тәтеш районы 360 млн сумлык ярдәм күрсәткән. «Унике автомобиль җибәрдек, тагын икене җибәрергә торабыз. 660 тонна йөк илттек. Егетләрнең үзләре белән очрашып торабыз. Үзем дә 25 мәртәбә махсус хәрби операция зонасына барып кайттым», – дип сөйләде район башлыгы Рәмис Сафиуллов.

Әлмәттә хәрбиләрнең гаиләләре белән элемтәдә торып, аларга ярдәм итү өчен махсус штаб төзелгән. «Алар көненә 24 сәгать, атнасына 7 көн элемтәдә тора. Булган проблемаларны мөмкин кадәр тизрәк хәл итәргә тырышабыз. Волонтерлар, битараф булмаган һәркем – барысы да ярдәм итәргә атлыгып тора», – диде район башлыгы Тимур Нагуманов.

Чаллыда исә хәрби операция зонасына контракт төзеп китүчеләргә 200 мең сум күләмендә өстәмә акча түләнә. «Гаиләләрен дә игътибарсыз калдырмыйбыз. Ватан алдындагы бурычын үтәүчеләрнең хатыннары сабыйлар алып кайта. Мин үзем дә 37 бала өчен икенче әти булдым. Һәр әнине шәхсән котларга тырышам. Аларга шулай ук 100 мең сум күләмендәге акчалата ярдәм дә тапшырыла», – диде шәһәр мэры Наил Мәһдиев.

Данила АБРАМОВ, махсус хәрби операциядә катнашучы егет, рота командиры урынбасары:
– Ватанга карата мәхәббәтне әти-әнием кечкенәдән сеңдерде. Алар рухымны күтәреп тормаса, авыррак булыр иде. Ватаным алдындагы бурычымны үтәргәме-юкмы, дигән сорау башыма да килеп карамады. Безгә көн саен диярлек ни дә булса килеп тора. Балалардан хатлар алу аеруча рәхәт. Ә өйгә кайтканда, әбием пешергән пилмәннәрне сагынып кайтам. Якыннарымның күләч йөз белән каршы алуы шулай ук күңелле.

Евгения КОЦАРЬ, «За Победу! Казань» гуманитар хәрәкәтен оештыручы:
– Ирем хәрби операциягә киткән вакытта, беренче сабыебызны көтә идем. Билгеле, аны озату, аның карарын кабул итү бик авыр булды. Ләкин мин аның рухын күтәрү өчен бик тырыштым. Без, хәрбиләрнең хатыннары, ирләребез өчен барына да әзер.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Мәдәни мирас ни хәлдә?

Тарихи кыйммәткә ия булган биналарны саклау буенча республикада нинди эшләр башкарыла? Татарстан Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә әнә шул хакта сөйләштеләр.

Әлеге эшләр турында Татарстан Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе Иван Гущин сөйләде.

– Берничә объект реставрация көтә. Аларда без инде төп әзерлек этапларын уздырдык һәм фәнни-проект документларын әзерләдек, – диде комитет рәисе. – Гомумән алганда, бөтен республика буенча йөзләгән объектта эш алып барыла, аларның һәрберсе күз уңында. Һәйкәлләрне заманча файдалануга җайлаштыру – мөһим мәсьәлә. Шул ук вакытта үзенчәлеген һәм кыйммәтен саклап калу зарур. Бу гади бурыч түгел, әмма республикада уңышлы тормышка ашырыла.

Шулай итеп, тиздән Балтач районында XIX гасырда төзелгән Мортаза Мөлеков фабрикасы, Алабугада Екатерина прогимназиясе биналарында, Минзәлә драма театрында, Арча районында Тукай дәүләт әдәби-мемориаль музеенда эшләр башларга ниятлиләр. Болардан тыш, исемлектә Бөгелмәнең «Халык йорты» һәм Мамадыштә олимпия резервының республика спорт мәктәбе урнашкан сәүдәгәр Жуков йорты бар.

Бу җәһәттән Казанда нинди эшләр башкарыла соң? Янгыннан зыян күргән Алафузов театры бинасында тезекләндерү эшләре бара. «Мәрҗани» мәчетендә дә күптән көтелгән ремонт эшләре башланган. Фундаментлы ныгытыла, фасады һәм түбәсе тәртипкә китерелә. Реставрация эшләре берничә этапта узар дип көтелә. Кукмара районының Мәчкәрә авылындагы иң борынгы мәчетләрнең берсендә дә ремонт эшләре гөрли. Анда котельный һәм тәһарәт алу урыны җиһазландырылачак.

Узган ел Биектау районының Айбаш авылындагы мәчетнең манарасы ауган иде. Аллаһ йорты хәзер нинди хәлдә соң? Иван Гущин әйтүенчә, бу мәсьәлә хәл ителгән, ул да тезекләндерелә.

Быел республикада 30дан артык мәдәни мирас объекты реставрациялә. Бу максатларга бюджеттан 4 млрд сумга якын акча бүлеп бирелгән. Иван Гущин билгеләп үткәнчә, эшләрне финанслау өстенлекле бурычларны һәм объектларның техник торышын исәпкә алып башкарыла.

Тагын бер борчыган мәсьәлә – Сөембикә манарасы торышы турында да белешлек.

– Сөембикә манарасының кирпеч өлеше җимерелгән урыннар бар, әмма бүген аңа бернинди дә куркыныч янамый. Бинаны, лазер технологияләре кулланып, тикшерүләр үткәрәде. Манара тагын да авышкан, дигән мәгълүмат юк, – дип аңлатты комитет рәисе.

Ләйсән САФИНА

ЧЫН ЕГЕТЛӘР

«Татар-информ» / Айдар Фархан

Кича «Все СВОи» патриотик акция кысасында Казанның «Җиңү проспекты», «Авиатөзелеш» метро станцияләре янәшәсендә, Мәскәү базары янында, Бауман һәм Петербург урамнарында пикетлар узды. Анда ир-егетләргә контракт буенча хезмәт турында мәгълүмат бирделәр.

– Халык бик кызыксына. Контракт буенча килешү төзегән ир-атларга нинди ярдәм күрсәтеләгенен килеп тә сорыйлар. Ташламаларны да белəселәре килә. Телəге булганнар өчен кая мөрәҗәгать итәргә икәнен аңлатабыз, – ди волонтер Александра Воробьева.

Казанның Вахитов районында яшәүче Кәүсәрия Хановаынын улы махсус хәрби операциядә. Ана улының ялга кайтуын көтә.

– Мин баламны ялгыз үстердем. Әтисе вафат булганда, аңа нибары 4 яшь иде. Чын ир-ат булсын дип тырыштым. Шөкер, батыр йөрәкле, кыю бала булды. Повесткаы беренче көнне үк тапшырдылар. Улым, барам, диде. Мин тел догада. Улыма атап, корбан да чалдырган идем. Үзе ялга кайткач, аш уздырам, – ди Кәүсәрия апа.

Виктор Никитинга – 58 яшь. Хәрби хезмәтне Севастопольдә үткән. Сәламәтлеге мактанырлык түгел. Өлешчә мобилизация башлангач ук, үзен алуларын сорап, хәрби комиссариатка барган. Әмма кире борганнар.

– Киявем, улым анда. Шуларны уйлыйм да үз-үзәмә: «Виктор, син монда нишләп ятасың?» – дим. Ике да уйлармыйча китәр идем. Тик хатыным елый, кызым белән киленем: «Синсез нишлик?» – ди. Онкыларны төрле тугәрәкләргә йөртү минем өстә. Берсен укырга илтәм, икенчесен йөзүгә, өченчесен биюгә, – ди ул. – Безнең бабайлар Ватан өчен утка-суга кергән. Аларга хәзерге кебек акча түләмәгәннәр, ташламалар бирмәгәннәр. Йөрәкләрендә илне ярату көчле булган. Яшь буынга чын ир-ат тәрбиясен бирәсе иде. Туган җирен яраткан ир-ат Ватанны сакларга тиеш.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Җәһәт әңгәмә

Балтачта центнер түгел, тонна дип сөйләшәләр. Көненә 400 тоннадан артык (!) сөт савалар. Быел бөртеклеләрдән 100 мең тонна уңыш алганнар. Хәрби операциягә 167 тонна гуманитар ярдәм җибәргәннәр. Балтач районы башлыгы Рамил НОТФУЛЛИН белән авыл хуҗалыгы тармагы, хәрби операциягә ярдәм, укытучыларга хөрмәт турында сөйләштек.



:: Рамил Рәшитович, авыл хуҗалыгы районы буларак, халыкның, үзегезнең кәефегез ничек?

– Ел үзенчәлеклерәк булуга карамастан, Аллаһка шөкер. Яз коры һәм суык булгач, башта бик курыккан идек. Җәй дә яңгырсызлыгы белән сынады. Мине бигрәк тә яз белән җәй түгел, көзге һава торышы аптыратты. Авыл хуҗалыгында утыз елдан артык эшләп, мондый көзне хәтерләмим. Август, сентябрь айлары коры килде. 2009 елда да көз быелгы кебек үк булмады. Көзге уҗымнарның тишелеше начар, нигездә юк һәм булмаячак. Игенчелектә исә быелгы уңыш без көткәннән күпкә югарырак булды. Кышлату чорына җитәрлек күләмдә терлек азыгы хәзерли алдык. Бу бик мөһим. Ни өчен дигәндә, республикада шәхси, фермер хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы җәмгыятьләре белән бергә, иң күп мал – бездә. Районда 60 мең баштан артык терлек бар. Җир мәйданы буенча районыбыз – урта тирәдә. Терлек азыгын, нигездә, үзебезнең күпьеллык үләннәр хисабына әзерли алдык. Люцерна, кукуруз – сенаж һәм силос хәзерләүдә төп культуралар. Быел кукуруз культурасын 9 мең гектардан күбрәк мәйданда иктек. Башка елларга караганда, күләмен ике мәртәбә арттырдык. Хәзерләнгән терлек азыгы күләме бер шартлы терлеккә 28 центнер азык берәмлеген тәшкил итә. Узган елдан калган запас белән 40 центнердан артыграк. Бу – бик яхшы күрсәткеч. Бер шартлы терлеккә 60 центнер күләмендә азык туплаган хуҗалыклар да бар.

:: Уҗымнар булмаячак, дисез... Быелгы көзнең сабакларыннан нинди нәтиҗә чыгардыгыз?

– Ел елга охшап килми. Соңгы елларда һава шартлары көзге уҗымнар өчен уңай булмады. Көздән уҗымнар ныклап үсеп китмәсә, язга бик өмет итеп булмый. Шуңа күрә быел көзге уҗымнарның мәйданын киметеп, 5 мең 200 гектарда гына чәчтек. Быел арышның да бәясе түбән. Терлек азыгын күп хәзерләгәч, бөртекләрне кая урнаштырыйк, дип аптырамыйбыз. Һәр хуҗалык үзе эшкәртеп, складка салып куя. Бөртекнең 70 проценты терлек азыгына китәчәк.

Узган ел игеннәр уңышы 130 мең тоннаны тәшкил итте. Быел шуның яртысын җыя алсак та, әйбәт булыр, дип көткән идем. 100 мең тонна уңыш җыеп алдык. Алдагы ел белән чагыштырсак, аерма күп түгел. Соңгы елларда кукурузны бөртеккә игү белән шөгыльләнәбез. Аны 6 мең тоннадан күбрәк тупладык. Кукуруздан башка мул сөт савып булмый. Җылы һава торышы кукуруз бөртеген уңай шартларда сугып алырга мөмкинлек бирде.

:: Утыз елдан артык авыл хуҗалыгында эшләгән җитәкче буларак әйтегез әле, мондый үзгәрешләргә алдан ук әзер торып була идеме? Авыл хуҗалыгы технологияләр, фән ягыннан гадәттән тыш хәлләргә әзерме?

– Әзерлек күпмедер бар инде ул, чөнки технологияләр үзгәрә. Коры елларда культураларны яфрактан тукландыру – үзен аклый торган алымнарның берсе. Яз көне берничә хуҗалык көзге культураларга сыек ашламалар кертү ысулын куллана. 2010 елгы корылыктан соң мелиорация буенча программалар кабул ителде. Ул вакытта сатып алынган җиһазның 90 процентына субсидия бирелде. Бездә дә әлеге ярдәмне берничә хуҗалык алды. Хәзер республикада шул программаларны кайтару буенча эш алып барыла. Әмма мелиорация җиһазлары бәясенең 10 процентын гына түләп сатып алу мөмкинлеге бетте. Бу мәсьәләдә дәүләт ярдәме күбрәк кирәк дип саныйм. Бүген кайбер хуҗалыклар бәрәңгене сугарып үстерә. Коры елларда өстәмә сугару үзен аклый, ә уртача җылы җәйләрдә ул кирәк тә түгел кебек. Әмма елларның төрлесе була. Соңгы елларда җирне тирән эшкәртүгә игътибар бирәбез, чөнки бу алым көзге, язгы дым запасын саклап калырга мөмкинлек бирә. Техника сатып алганда да дәүләт ярдәме күбрәк булса иде. Запас частьларны Казахстан, төрле илләр аша кайтарабыз. Бу яктан артык зур проблема юк.

ЭШЛЕ АШ

Быел тугыз айда районда 264 сабый туды, узган ел белән чагыштырганда, 72гә күбрәк. Үлем очраклары – 251, былтыргыдан 46га кимрәк. Язылышучылар саны 32гә азрак. Быел 114 пар никахлашты, аерылышучылар узган елдагы белән бер чама – 51.

:: Татарстан Рәисе шәхси хуҗалыклардагы терлек мәсьәләләренә игътибар бирә һәм, баш санын киметмәскә, дигән бурыч та куя. Шуңа карамастан, сөт, ашлык бәясе түбән булудан зарланучылар да аз түгел. Бу уңайдан Балтачта вазгыять ничегрәк?

– Сөт бәясе буенча төрле елларны күрдек. Без сатып ала торган һәрнәрсәнең бәясе артып тора. Шул вакытта сөтнең бәясе төшә. Башка күсәк белән суккан кебек бит бу. Август, сентябрьдә сөт бәясе 4 сумга артты. Әмма узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, аерма 6–7 сум калды. Шәхси хуҗалыктан сөт җыю бәясе – 26–27 сум. Сөтнең сатып алу бәясе тиешле югарылыкта булса, бернинди субсидия дә кирәкми.

Районда терлек саны артты дип тә, кимеде дип тә әйтә алмыйм. Шәхси хуҗалыкларда 17 мең 576 баш мөгезле эре терлек исәпләнә. Узган ел белән чагыштырганда, 161гә кимрәк. Бу – 1 сентябрьгә кителгән мәгълүмат. Сыерлар саны – 7300, узган елгыдан 40 башка күбрәк.

:: Махсус хәрби операциягә ярдәм итү буенча нинди чаралар оештырасыз?

– Балтач районыннан 165 ир-егет мобилизацияләнде. Узган ел 10лап егет, быел 34 егет контракт нигезендә хәрби хезмәткә китте. Киңәшмәләрдә хәрби операция темасын еш күтәрәбез. Район халкы бу изге эштә бик актив. Волонтерларыбыз кайнап тора. Лена Вәлиева үзе генә дә Лисичанскидагы ятимнәр йортларына, солдатларга берничә мәртәбә ярдәм илтте. Әфган, Чечня сугышында булганнар да бик актив. Бина сорасалар, табып бирәбез. Мичләр ясарга урын кирәк, диделәр. Гозерләрен үтәргә тырышабыз. Авыл хуҗалыгы оешмалары ягулык белән ярдәм итә. Эшмәкәрләр белән бәрәңге, яшелчәләр җибәрдек. Районнан барлыгы 51 рейс белән 167 тонна гуманитар ярдәм китте: азык-төлек продукциясе – 112 тонна, гигиена кирәк-яраклары – 2 тонна, кием-салым – 5 тонна... 3 «УАЗ», 1 «Нива» машинасы илттек. Барлык ярдәм 48 миллион сумлап тәшкил итте.

Хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренең хәлләре белән даими кызыксынабыз. Кемдер су, мунчасына газ кертү, йортын төзекләндерүне сорый. Кемгәдер утын кайтартырга, койма тотарга кирәк. Һәрчак ярдәм күрсәтеп киләбез. Хәрбиләр белән дә элемтәдә торабыз. Алар артык зур проблемалар күтәрми.

:: Балтач – Укытучылар һәм остазлар елында мөгаллимнәр өчен күп чаралар уздырган районнарның берсе. Укытучыларның абруен күтәрүгә тиешле игътибарны биреп җиткерәбез, дип саныйсызмы?

– Дөресен әйткәндә, биреп бетерә алмыйбыз. Елны укытучыларга багышлау бик дөрес. Көндәлек проблемалар белән күп әйберләр онытыла. Югыйсә, ныклап уйлап карасаң, барысы да укытучылар хезмәтеннән башлана бит. Беренче укытучым күптән вафат. 4–8 нче сыйныфларда Рәйсә апа Фәтхетдинова җитәкчебез булды. Бәйрәмнәрдә аны онытмыйбыз.

Быелгы Сабан туенда укытучылар династияләрен җыеп, бүләкләп уздык. 30дан артык укытучы гаиләләре килгән иде. Ветеран укытучыларны паркларда йөртеп, чәйләр эчердек. Укытучылар көнендә 120дән артык укытучыны төрле дәүләт бүләкләре, мактау кәгазьләре белән бүләкләдек. 850ләп укытучы һәм тәрбиячегә бүләкләр тутырдык. Мәгариф хезмәткәрләренә кулдан килгәнчә игътибар бирергә тырышабыз.

Соңгы елларда физика, математика, химия, инглиз теле укытучыларына кытлык бар, әмма хезмәт бүленешен көйләү хисабына, кадрлар мәсьәләсен хәл итеп барабыз.

Сәрия МИФТАХОВА

ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ РӘИСЕ УРЫНБАСАРЫ МАРАТ ӘХМӘТОВ:

«ТЕЛЕБЕЗНЕ БЕРГӘЛӘП ЯРАТЫЙК»

«Европа цивилизациясенең язу тарихы һәм Россия халыкларының язма мәдәнияте» дип аталган халыкара фәнни конференциядә Марат Әхмәтов әнә шундый өндәү белән чыкты.

Аның: «Мин гектарлар, центнерлар, тонналар белән эш иткән кеше инде, сезнең арага кереп кенә барам», – дигән сүзләрен бөтенләй кабул итмәделәр. Чыннан да, Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясен җитәкли һәм матур гамәлләре белән сөендерә башлавына да байтак бит инде.

– Безнең телебез бик бай һәм үзенчәлекле. Аны яратмаска мөмкин түгел, – дип, чын күңелдән әйтә бит үзе дә.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов исә туган телебезнең тарихына тукталды. Элек татар телендә патша указлары чыкканын, хәтта дипломатлар арасында да киң кулланыш тапканын чыгыш ясаучылар берничә тапкыр искәрттеләр.

Казанда мондый чараны үткәрү нияте Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның татар зыялылары белән очрашуыннан соң туа. Татарстан Фәннәр академиясенең теләктәшләре дә күп була: оештыру эшенә Россия Фәннәр академиясенең Санкт-Петербург Тарих, Рус теле институтлары, китапханә, архивлары, шулай ук Татарстанның милли китапханәсе алына.

Һәр кеше яхшы белә: тарихыбыз бик катлаулы, әле өйрәнелмәгән әйберләр дә бик күп. Шуңа күрә бу чарадагы темаларның төрлелегенә дә гаҗәпләнәсе юк. Менә аларның кайберләре: гарәп графикасындагы язма чыганаклар, кириллицадагы документлар, яңа һәм иң яңа гасыр язмачылык традицияләре, Россия халыкларының язма мәдәнияте, грек һәм латин кульъязмалары, яһүд, әрмән, Пермь һәм катнаш традицияле язмачылык һәм башкалар.

Сөйләп кенә калмадылар, әлбәттә. Шушы теманы үз эченә алган күргәзмәне килгән кунаклар да, галимнәр дә, студентлар да, журналистлар да бик кызыксынып карады. Әле ул гына да түгел. Залда каллиграфия буенча мастер-класслар оештырылган иде. Бигрәк тә студентлар өстәл янынннан һич кенә дә китәргә ашыкмадылар.

Чыгышлар вакытында без халыкларыбызның нинди тыгыз элемтәдә яшәүләренә тагын бер кат инандык. Европа цивилизациясендә гарәп язмачылыгы, рус китапчылыгында редакторлык тибындагы язу, Үзбәкстан Республикасы Көнчыгышны өйрәнү институтының гарәп язулы кульъязмаларны саклау, казах тел белемендә язу теориясе өлкәсендә заманча эзләнүләр, төрки-азәрбайҗан цивилизациясе тарихында гарәп язмачылыгының социаль-мәдәни роленә багышланган чыгышлар шул хакта сөйләде.

Өч көн буе барган конференциядә 100 әйдәп баручы галим катнашты. Россия төбәкләреннән дә, чит илләрдән дә килгән алар. Галимнәр өчен бу бер дә гайре табигый хәл түгел. Тарихыбызны өйрәнергә безгә беренче чиратта әнә шул бердәмлек ярдәм итә дә инде.

Конференция кысасында Татарстан Милли китапханәсендә «Европа һәм Көнчыгыш цивилизацияләренең язу тарихы» дигән күргәзмә эшли. Анда Санкт-Петербургтан китерелгән экспонатлар да бар.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Приложение
к постановлению Центральной избирательной
комиссии Республики Татарстан
от 17 октября 2023 г. № 26/176

**Сообщение
Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан о приеме предложений по кандидатуре члена избирательной комиссии с правом решающего голоса в состав территориальной избирательной комиссии Тукаевского района Республики Татарстан на вакантное место**

В связи с прекращением полномочий члена территориальной избирательной комиссии Тукаевского района Республики Татарстан с правом решающего голоса, руководствуясь статьями 22, 26 и 29 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации», статьями 11, 15 и 18 Избирательного кодекса Республики Татарстан, Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан объявляет прием предложений по кандидатуре для назначения члена территориальной избирательной комиссии Тукаевского района Республики Татарстан с правом решающего голоса.

Прием документов осуществляется в период с 19 октября по 23 октября 2023 года по рабочим дням с 09.00 до 18.00 часов (перерыв на обед – с 12.00 до 13.00 часов), по адресу: ул. Батурина, д. 7Б, г. Казань, 420111 (контактный телефон: 8(843) 292-84-33).

При внесении предложений по кандидатуре в состав территориальной избирательной комиссии на вакантное место необходимо руководствоваться Постановлением Центральной избирательной комиссии Российской Федерации от 15 марта 2023 г. №111/863-8 «О методических рекомендациях о порядке формирования территориальных, окружных и участковых избирательных комиссий». Образцы необходимых документов размещены на официальном сайте Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Авыл капкасы

«ЯРАТУЫМ БЕЛӘН ҖИҢДЕМ»

Россиянең иң шәп сыеры Татарстанда тәрбияләнгәнлеген белә идегезме әле? Иң матур, төз гәүдәле һәм сөтләч. «Кызыл Шәрык Агро» җәмгыятенең Рус Әҗәлесе комплексындагы Дочка кушаматлы сыерның даны әнә шулай еракларга таралды. Аны нинди сыйфатларына карап сайлап алганнар, бәйгегә әзерлек ничек барган? Без шул турыда белештек.

yashel-uzan.ru

Дочка республикада узган «Бөтенроссия кыр көне – 2023»тә иң яхшы сыер булып танылган иде инде. Шушы көннәрдә исә аңа титулын Мәскәүдә узган «Алтын көз» XXV Россия агросәнәгате күргәзмәсендә тагын бер кат исбатларга туры килә. Сөтлебикә монда да сынатмады: алтын медаль белән кайтты.

Мондый чара быел беренче тапкыр уздырылды. «Бөтенроссия кыр көне»ндә Мари Эл, Мордовия, Удмуртия, Чувашия республикалары, Ульяновск өлкәсе һәм Татарстаннан 52 хуҗалыктан 80 сыер катнашкан иде. Җиңүчеләрне дә чын гүзәллек бәйгесендәге шикелле бәяләделәр. Подиумнан узган иң яхшы сыерны гәүдә төзелешенә, күкрәк киңлегенә, арка сызыгына, йөрүенең гармониялелегенә, җилен формасына, продуктивлыгына һәм башка сыйфатларына карап ачыкладылар.

Хендлерга, ягъни сыерны күргәзмәдә йөртүче Гөлчәчәк Сәлахиевага исә бәйге алдыннан яңа һөнәр үзләштерергә туры килгән. Ул «Кызыл Шәрык Агро» җәмгыятенең «Вахит» хуҗалыгында 2003 елдан бирле бозаулар карый.

– Безнең әни гомер буе сыерлар сауды, шуңа күрә мин дә гел аның кул арасына кереп йөрдем. Мин малларны бик яратам. Үз хуҗалыгыбызда да терлекләр күп асрыйбыз. Авыл кешесенең терлеккә җаны тарта аның, шуңа күрә хайваннар да безне тыңлыйдыр дип уйлыйм, – ди ул.

Булачак чемпионны әзерләр өчен берничә кеше арасыннан Гөлчәчәк Сәлахиеваны «Үткенлегегез, чаялыгыгыз бар, куркып та калмыйсыз. Сез булдырасыз!» – дип сайлап алганнар. Ул да сынатмаска сүз биргән. Һәм өч ай дәвамында бәйгегә бик тырышып әзерләнгән.

– Мал бит инде ул. Шуңа күрә өйрәтү җиңел түгел, төрле чаклар булды, – дип искә алды ул сөтлебикәне бәйгегә әзерләгән вакытларын. – Иң элек безгә берничә сыерны алып килделәр. Арадан иң усал дигәне, якынлашуга, миңа таба башын сузды. «Болай булгач, өйрәнә икән», – дидем дә шунысын сайлап алдым. Сыер баштагы вакытта янына да китермәде. Өстерәп тә чапты, астында да калдык, егылып, кулларны да авырттырдык. Ләкин ахырга таба барыбер буйсындыра алдык. Тәмле сүзләрне, ягымлылыкны, яратуны эшкә җиктем. Үз хуҗалыгымда бозауларны карыйм да 2–3 сәгатькә күрше авылга сыерым белән очрашуга барып килә идем. Акрынлап аркасыннан сыйпап, муенын яраттыра башлады. Сөтлебикәне җитәкләгән кеше нәрсә эшли, сыер да шуны ук кабатларга тиеш. Анысын да булдырдык. Сыер күзләрен мөлдерәтеп карап тора иде безгә. Аның карашын күргәч, үземнең дә күзләремнән яшьләр килде.

Сыерны жюрига тәкъдим итәсе кешегә өч ай вакыт бирелсә, катнашасы сыерны 1900 баш арасыннан физик күрсәткечләрен карап, генетик потенциалын тикшереп, бер атна эчендә ашауның савымны ничек яхшыртуын күзәтеп, узган ел ук сайлап алганнар.

– Сыерым бик биек, зур гәүдәле, матур иде. Сөбханалла! Аяклары озын, җиленнәре матур, үзе сөтләч. Тәүлегенә 45 литр сөт бирә. Дөрес, Мәскәүгә баргач, стресстан сөтен 35 литрга кадәр киметте, тик бер көннән үз продуктивлыгына кайтты, – дип горурланып сөйләде сөтлебикәсе турында Гөлчәчәк Сәлахиева. – Усал дисәләр дә, тыңлата алдым мин аны. Башка төбәкләрдән килгән сыерларны дүртәр кеше җитәкләп йөртте. Безнеке мине генә дә тыңлады. Акыллы иде. Подиумнан йөрткәндә, башына калфак та кидерттек әле без аның! Гомумән, бәйгедә безнең сыерга тиңнәр булмады. Иң матуры, иң чистасы һәм иң нык әзерлеклесе безнеке иде! Без бит аны шампунь белән яхшылап юып, йоннарын тигезләп кисеп, ялт иттереп чыгардык. Бәяләүчеләр дә шаккатып: «Сез бик нык әзерләнгәнсез», – диделәр.

Мәскәүдән кайткач та, сыерын елап озатып калган ул. Әле шушы көннәрдә үзе кунакка да барып килмәкче икән. Менә шундый булдыклы сыерларыбыз да, уңган һәм тәвәккәл кызларыбыз да бар безнең!

Зөһрә САДЫЙКОВА

Яшәеш

Әти назы кирәк

Әтиләр – ил тоткасы! Гомер-гомергә ир-ат гаиләне саклаучы, яклаучы булып тора. Татарстанда әтиләр 2008 елдан бирле бергә җыелып эшлиләр. Әтиләр берлеген ниләр борчый? Татарстанның Иҗтимагый палатасында узган «Җаваплы әти булу» дигән «түгәрәк өстәл»дә шул хакта сөйләштеләр.

Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова ассызыклаганча, әтиләрнең җәмгыятьтә роле зур.

– Әтиләр гаиләсе, баласы, Ватаны, иле өчен җаваплы. Әле киләсе елларда бәйрәмнең кадере, кирәклеге артачак, – диде ул. – 2008 елда Түбән Камада Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев белән хәйрия эшләре буенча утырыш уздырдык. Шунда 11 бала үстерүче, шәһәр хастаханәсендә эшләүче ир-ат чыгыш ясады. Ул анда: «Гаиләдә иң мөһиме – әтинең аңлавы һәм терәк булуы», – дип әйткән иде. Ул чакта Түбән Камада Әтиләр берлеге оештырылган иде инде. Алар, чит балалар юк, минем сабыемның дуслары бар, дигән девиз белән эшләде. Хәйрия утырышыннан соң Минтимер Шәймиев Татарстанда шундый берләшмә кирәклеген әйтте.

Махсус хәрби операциядә катнашучы ир-атлар хакында да сөйләделәр бу чарада. Лилия Кутушеваның ире – беренче көннәрдән үк Ватан сагында. Ул да үзенең тәкъдимнәрен җиткерде.

– «Өлешчә мобилизация» дигән сүз кагылмаган кешеләр ирләрен, балаларын Ватан сагына озатканнарны бик аңлап та бетерми кайчак. Мине мәктәпләрдәге күренешләр борчый. Әтиләре ил сагындагы балаларны башкалардан аерып карарга кирәкми дип уйлыйм. Әтиләре янәшәсендә булмаганнар өчен авыр бит ул, – ди Лилия. – Тагын бер үтенеч: әтиләре ялга кайткач, мәктәпләргә килеп, видеога төшерүләр бетсен иде. Баланы ике атнага укудан азат итеп, әтисе янына кайтарудан да яхшысы юк.

Очрашуда гаиләдәге аерылышуларны булдырмау, балаларга терәк булу турында да фикерләр булды. Белгечләр әйтүенчә, әтиләре махсус хәрби операциядә һәлак булган балалар белән эшләү җиңел түгел. Алексей Сандригайло, берничә спорт клубы белән сөйләшеп, балаларны шунда җыймакчы була. Кыскасы, эшләнәсе эшләр күп әле.

Тагын шунысын да әйтик: «Әтиләр берлеге»ндә йөрәге кушканнар эшли. Моның өчен акча түләнми. Айдар Әшрәпов – шундыйларның берсе. Ул яшь гаиләләр белән эшли.

– Яшь гаиләләр белән эшләүгә җаваплы кеше буларак, төрле хәлләр белән очрашам. Күптән түгел Яшел Үзәндә йортлары янган бер гаиләгә ярдәм иттек, – ди ул. – Яшьләр арасында аерылышучылар күп. Андый чакта гаиләләрне саклап калыр өчен, кулдан килгәнне эшлибез. Һәркем баласына, гаиләсенә игътибарлы булсын иде. Эш дип, өйдәгеләрне онытмыйк. Вакыт табыйк, күбрәк бергә булыйк.

Әтиләр нинди булырга тиеш соң? Әлеге сорауны Биектау районында яшәүче Габбас Галәветдиновка бирдем. Хатыны бакыйлыкка күчкәндә, кулында берсеннән-берсе кечкенә ике сабые кала аның. Олысына – 4, кечесенә 2 яшь тә булмый.

– Бала әтисенә ышанырга, аның ярдәмен тоярга тиеш. Аерылышып, алимент түләмичә, сабыеның хәлен белмичә йөрүче кеше әти буламыни ул? Ир белән хатын арасына баланы кертмәсеннәр, – ди 65 яшьлек Габбас абый. – Ике кызым да буй җитте. Берсе кияүдә, балалары бар. Хәлемне белеп, кадерләп торалар. Авыр чаклар артта калды инде. Мин – бик бәхетле әти. Кадерле картлыгың балалардан тора! Шуны онытмыйк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«КАРА АЛТЫН»ЛЫ ЮЛ

РОМАШКИНО ЧЫГАНАГЫНА 75 ЕЛ

Бу шәхес «кара алтын» табу эшенең бөтен нечкәлекләрен белә. Ул хакта сәгатьләр буе тәмләп, тәфсилләп сөйли ала ул. Шулай булмый ни! Беренче көннәрдән үк Татарстанның нефть тармагын үстерүгә зур өлеш керткән шәхес бит ул! Сүзебез – «Татнефть» оешмасының мактаулы ветераны, Татарстанның атказанган нефтьчесе Рашад Фәткуллин турында.

ТАТАРСТАН НЕФТЕНӘ 80 ЕЛ

Танылган нефтьченең балачагы дәһшәтле сугыш елларына туры килә. Совет-фин сугышында катнашкан әтиләре янәдән фронтка – көнчыгышта японнарга каршы сугышырга китә. Әмма гаилә башлыгына туган якларына исән-сау әйләнеп кайтырга насыйп булмый. Әтисе вафат булгач, Рашад әнисенең иң төп терәгенә әверелә. Нефть тармагына да әнисенә азмы-күпме ярдәм итү теләге алып килә аны.

– Гаиләне яшәтергә кирәк бит. Нефть вузында исә стипендия башка югары уку йортлары белән чагыштырганда ике тапкыр диярлек күбрәк иде. Кием-салымны да бушка бирәләр. Шуңа күрә нәкъ менә биредә укырга карар кылдым. Конкурс зур иде. Бәхеткә, имтиханнарны уңышлы гына тапшырып, укырга кердем, – дип искә ала Рашад Фәткуллин «кара алтын» өлкәсенә тәүге адым ясаган көннәрен.

Уфаның нефть институтын тәмамлаган егетне юллама белән Әлмәт шәһәренә эшкә җибәрәләр. Татарстанда нефть сәнәгатенең тулы куәткә чәчәк атып килгән чагы була ул. Шуңа нәкъ менә шушы төбәккә эшкә җибәрүләренә шатланып туя алмый егет. Үзенең хезмәт юлын скважина бораулаучы буларак башлаган Рашад Фәткуллин нефть табу эшенең бөтен баскычларын үтә. Верховой, бораулаучы ярдәмчесе, бораулаучы, бораулау мастеры, смена инженеры, баш инженер да була, 1 нче бораулау конторасы җитәкчесе вазыйфаларын да башкара ул.

1979 елда исә Рашад әфәндене үтә җаваплы вазыйфага билгелиләр. 1995 елга кадәр «Татнефть» оешмасы генераль директорының бораулау эшләре буенча урынбасары булып эшли ул. Шул рәвешле ул елларда нефть гигантының иң төп һәм мөһим юнәлеше Рашад Фәткуллин җилкәсендә була.

– Татарстандагы нефть тармагын гына күтәреп калмадык. Ул елларда бар дөньяны гизәргә туры килде. Үзбәкстан, Казахстан, Украинада, хәтта Төркиядә, Һиндстанда да нефть чыгардык. Татарстанда, Себердә елына меңәр скважина төзедек. Минем кул астында егерме мең кеше эшләде. Мәскәүнең кышкы салкыннарыннан кисәк кенә 40 градус эсселектән әлсерәгән Һиндстанга барып, шуннан туры Себергә киткән вакытлар да булды. Елның 100 көне командировкада үтә иде. Нефть тармагының ни дәрәҗәдә куәтле чоры булганлыгын шуннан аңлагыз инде, – дип искә алды ул елларны Рашад әфәнде.

Бораулау эше өчен җаваплы кешегә шулар белән беррәттән башка мәшәкатьләр дә өстәлә. «Кара алтын» чыгару эшендә катнашкан эшчеләрне торыр урын, ашар ризык белән тәэмин итү ягын да кайгыртта. Башка төбәкләрдән әледән-әле эшкә чакырып торсалар да, Татарстанга, хезмәт юлын башлаган «Татнефть» оешмасына тугры калган ул.

„«Татнефть» – Советлар Союзы нефть сәнәгатенең чишмә башында торган оешма. Татарстан – файдалы казылмаларга бай төбәк. Нефть ятмаларына да бик бай ул. Катламның тирәнлеге 800 метр тәшкил итә. Ул Бөгелмәдән Алабугага кадәр сузыла. Бу байлык тагын йөз елга җитәчәк әле, – дип фаразлый тәҗрибәле нефтьче. – Бу өлкәдә кадрлар кытлыгы юк. «Кара алтын» табу эшен яшьләр үз итә. Димәк, алмашчылар булырмы дип тә борчыласы юк. Дөрес, хәзер инде нефтьне миллиард тонналап тапмыйбыз, күләме кими бара. Әмма Татарстан әйдәп баручы «кара алтын» төбәге булып кала бирә. Бездәге кебек көчле нефть тармагы башка бер җирдә дә юк һәм монда «Татнефть» оешмасының өлеше әйтеп бетергесез зур.

Алмашчылар дигәннән, бик күпләрне нефть табу эшенең асылына төшендергән Рашад Фәткуллин уналты еллап гомерен Әлмәтнең нефть институты студентларына белем бирүгә багышлаган. Студентларга дипом эшләрен фәкать инглиз телендә генә яклаттырган беренче мөгаллим дә ул. Рашад Фәткуллин бер үк вакытта фәннәр кандидаты – 70ләп фәнни мәкалә, 20ләп патент авторы да. Өч Хезмәт Кызыл байрагы ордены, И.М. Губкин исемендәге премия лауреаты, күпсанлы дәрәҗәле исем-бүләк иясе дә ул. Әмма берсе турында да кычкырып йөрергә яратмый Рашад әфәнде.

– Эштә уңышка ирешим дисәң, һәрчак укырга, эзләнергә, телләр өйрәнергә кирәк. Бигрәк тә инглиз телен белү мөһим. Бу – халыкара аралашу коралы. Шәхсән үземнең хезмәт юлымда бик нык ярдәм итте, – ди ул.

Рашад әфәнденең бу сүзләрен дәвам иттереп, уңышка ирешү өчен төгәллек тә кирәктер, дип өстисе килә.

Ник дигәндә, узган ел туксан яшен билгеләп үткән танылган нефтьче белән аралашканда, аның әнә шул сыйфаты да күзгә ташлана. Бер сүзе дә һавадан алып әйтелми: һәр сөйләгән тарихының фотодәлиле бар.

Гомерен «кара алтын» табуга багышлаган Рашад әфәнде тагын бер ягы белән шаккатырды. Баксаң, күңелдәге хис-кичереш, уйларын бик матур итеп шигырь юлларына да сала икән ул. Шигырьләре инде бер китаплык җыелган. Көзге моңсу көннәрдә төшенкелеккә бирелеп утыручылардан да түгел ул.

– Мин – оптимист. Теләсә кайсы ел фасылы кебек, көзнең дә – үз матурлыгы. Күрә белергә генә кирәк. Тормыш та шулай – матурлыгын күрә белгәннәргә генә матур, – ди Рашад Фәткуллин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүз уңаеннан, Рашад Фәткуллин – нефть сәнәгатен кино тарихына кертүгә дә зур өлеш керткән шәхес. Танылган режиссёр Андрей Кончаловский, «Сибириада» фильмында нефть чыгару күренешләрен төшергәндә, ярдәм сорап, нәкъ менә Рашад әфәндегә мөрәҗәгать иткән. Кама-Исмәгыйль янгын полигоны янында нефть вышкасы яну күренешен төшерергә ярдәм итә ул. Аның сценарием да үзе яза. Фильмда хәтта Рашад әфәндегә багышланган махсус юллар да бар. Ул чакта вышка ауган мизгелне берьюлы 20 камера төшергән. Башка кабатланмас мизгелләр бит! Тәҗрибәле нефтьченең даны монда да бик тиз тарала. Күп тә үтми Рашад әфәндегә, «Вне времени» дип исемләнгән фильмны төшергәндә киңәшче булуын сорап, «Мосфильм» оешмасыннан да мөрәҗәгать иткәннәр.

Рашад Фәткуллин башкарган һәр эше турында тәмләп, сагыну катыш горурлык белән сөйли.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сәламәтлек

Антибиотик язасы түгел! Тиздән табиблар ОРВИ белән авыручыларны дәвалаганда шушы кагыйдәне истә тотып эшли башлаячак. Ник дигәндә, Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы кискен тын юлы авыруларын дәвалау тәртибен үзгәртергә җыена.

КӘНФИТ ТҮГЕЛ

Проект авторлары фикеренчә, ОРВИны дәвалау тәртибен күптән үзгәртергә вакыт. Соңгы тапкыр бу кагыйдәләр моннан ун ел элек яңартылган булган. Шул вакыт эчендә вируска каршы күпсанлы көчле дарулар пәйда булды, ди проект авторлары. ОРВИны антибиотикларсыз гына дәвалый башлауга этәргән тагын бер сәбәпне атый алар. Баксаң, элегрәк ОРВИ белән авырган кешегә тулысынча терелеп аякка басу өчен ике атналап вакыт кирәк булган булса, хәзер бер атна дигәндә хәлләнәләр икән.

«Антибиотиклар вируслы авыруларны дәваламый. Шуңа күрә салкын тигәндә, отит, синусит, тонзиллит, бронхит вакытында аларны эчүдән бернинди файда да юк. Антибиотиклар бактериаль чирләр вакытында гына кулланылырга тиеш. Бу – инде күптән билгеле факт. Әмма күп кенә табиблар элекке гадәт буенча әле дә булса вируслы чир йоктырган кешегә антибиотик язуын дәвам иттерә. Соңгы арада аны кирәксә-кирәкмәсә, үз белдеге белән генә эчүчеләр саны да күбәйде», – диелә проектка аңлатма язуында.

Белгечләрнең сүзен халык арасында уздырылган соңгы тикшеренү нәтиҗәләре дә раслый. Илкүләм халык фикерен өйрәнү үзәге үткәргән сораштыруда ил халкының 26 проценты гына, салкын тиеп авырганда, иң беренче чиратта табибка күренүен әйткән. Калганнар андый чакта үз белдеге, таныш-белеш киңәше яки интернетта язылганнарга таянып дәвалана икән.

Республика клиник хастаханәсенең клиник фармакологы Альбина Звегинцева сүзләренә караганда, антибиотикларны теләсә ничек куллансаң, бактерияләр аның составындагы компонентларга ияләнә, аларга бирешми башлый. Шул рәвешле иң көчле бактерияләрне дә юк итәргә тиешле антибиотик аларга каршы тора алмый, аның организмга бер файдасы да калмый.

– Үз белдегең белән антибиотикның дозасын да азайтырга ярамый. Бу шулай ук бактерияләрнең антибиотикларга бирешмәвенә китерәчәк. Аларның дозасын арттырган очракта исә организмга тискәре йогынтысы башланырга, кеше агуланырга мөмкин. Гомумән, антибиотикларны табиб кушкан очракта гына эчәргә кирәк. Организмның антибиотикларга сизгерлеген тикшерү өчен, алдан бәвел анализы тапшырсаң да яхшы, ди белгеч.

Организм дару составындагы матдәләргә бик тиз ияләшә. Шуңа күрә кирәксә-кирәкмәсә антибиотик эчеп, организмны аңа ияләштерсәң, тагын да җитдирәк чирләр вакытында инде ул антибиотиклар бөтенләй тәэсир итмәскә мөмкин. Моның ни дәрәҗәдә куркыныч икәненә инану өчен, рәсми саннарга күз салу да җитә. Әйтик, 2019 елда антибиотикларга бирешмәс бактерияләр аркасында дөньяда 6 миллионлап кешенең гомере өзелгән. Чагыштыру өчен: шул ук елны СПИДтан Җир шарында 860 мең кеше үлгән. Галимнәр чаң суга: 2050 елга организмга антибиотиклар ярдәм итә алмау аркасында килеп чыккан үлем-китем очраклары кеше гомерен өзгән барлык мәкерле чирләр арасында беренче урынга ук чыгарга мөмкин.

Антибиотикларны, гадәттә, биш көн дәвамында эчәргә кирәк. Чирнең катлаулылыгына карап, табиб аны бер-ике атна дәвамында эчәргә дә кушарга мөмкин. Әмма күпләр өченче көнгә инде үзен яхшы хис итә башлый һәм дару эчүне туктата. Табиблар моны зур хата дип саный. Альбина Звегинцева моны түбәндәгечә аңлата:

„Болай эшләгәндә, бактерияләр даруга бирешмәскә әйләнәчәк. Шуңа күрә антибиотикларны ничә көн эчәргә кушылган булса, шулай эшләргә кирәк. Антибиотиклар эчә башлауга хәл яхшыру – аларның файдасы тия башлаган, табиб дөрес дәвалау курсы билгеләгән дигән сүз. Табиб көнгә ике тапкыр эчәргә кушкан икән, бу аларны иртә-кич кулланырга кирәк дигән сүз түгел. Бер төймәсен эчү белән икенчесе арасында 12 сәгать вакыт узарга тиеш. Көнгә өч тапкыр эчәргә кушылган икән, димәк, аны һәр 8 сәгать саен эчәргә кирәк. Антибиотиклар эчә башлагач, өч көн эчендә хәлегез яхшырмый, организмда уңай үзгәрешләр күзәтелми икән, кабат табибка мөрәҗәгать итегез.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5146 данә
Гомуми тираж – 13580 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 342

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+